ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.01.2026 ел Баулы шәһәре №1

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасының саклану корылмаларын саклап калу һәм алардан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2022 елның 7 апрелендәге 65 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

В соответствии с ПТатарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнар оборонасының саклану корылмаларын һәм гражданнар оборонасының башка объектларын саклап калу һәм алардан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2017 елның 2 маендагы 255 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 30 декабрендәге 1224 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасының саклану корылмаларын саклап калу һәм алардан нәтиҗәле файдалану чаралары турында» 2022 елның 7 апрелендәге 65 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - Гражданнар оборонасы объектларының сакланышын тәэмин итәргә, аларны файдалануга әзерлек халәтендә тоту һәм сыену урыннарыннан файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту чараларын күрергә;»;

2 пунктта икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - Гражданнар оборонасы объектларының сакланышын тәэмин итәргә, аларны файдалануга әзерлек халәтендә тоту һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту чараларын күрергә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров